# Тәкъдиргә иман китерү

## الإيمان بالقدر

اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

للإيمان أركان يقوم عليها ولا يصح إلا بها؛

**Иманның ул аларда нигезләнгән һәм ансыз дөрес булмаган баганалары бар.**

ومنها الإيمان بالقدر :

**Шул баганаларның берсе – тәкъдиргә ышану.**

وهو تقدير الله تعالى لكل ما يقع في الكون حسب ما سبق به علمه واقتضته حكمته

**Ягъни яшәештә нинди генә хәл булмасын - бу Аллаһның тәкъдире. Һәм һәрбер вакыйгәдә Аллаһның гыйлеме һәм хикмәте.**

وللإيمان بالقدر مراتب منها :

**Тәкъдиргә иман китерүнең дәрәҗәләре бар:**

-الايمان بعلم الله الأزلي أنه أحاط بكل شيء علما.

**– Аллаһның өзлексез гыйлеме барлыгына һәм Ул барлык нәрсәне Үз гыйлеме белән чолгап алганына ышану.**

وأنه علم ما كان وما يكون وماسيكون.
جملة وتفصيلا.

Аллаһ нәрсә булганын, нәрсә барын һәм ни булачагын тулысынча һәм җентекләп алдан ук белеп тора.

قال تعالى: إنّ الله بكلّ شيء عليم

Аллаһ әйтте: «Хакыйкатьтә, Аллаһ барнәрсәне дә белүче».

فلا يتجدد له علم بعد جهل، ولا يلحقه نسيان بعد علم.

Һәм Ул нидер белмичә соңыннан белү, я инде нидер белеп аннары оныту сыйфатыннан пакь. Аның гыйлеме гел булган һәм бу гыйлем мәңгелеккә калачак.

ومن الإيمان بالقدر الإيمان بالكتابة ؛ فنؤمن بأن الله كتب ما سبق به علمه من مقادير المخلوقات في اللوح المحفوظ.

– Шулай ук тәкъдиргә ышанудан – язмага ышану. Аллаһ ләүхуль-махфузда мәхлукларының язмышларын алдан ук язып куйган.

فكل ما جرى وما يجري وكلٌّ كائن إلى يوم القيامة مكتوب عند الله.

**Барлык үткән нәрсәләр, хәзерге вакыттагы хәлләр, шулай ук Кыямәт көненә хәтле булачак бар нәрсәләр дә Аллаһның китабында язылып куелган.**

قال تعالى: وكلّ شيء أحصيناه في إمام مبين.

**Аллаһ әйтте: «Без һәрнәрсәне санап аңлаешлы булган китапка яздык».**

وفي الحديث: إن أول ما خلق الله القلم فقال له اكتب فجرى بما هو كائن الى الأبد.

**Хәдистә әйтелгәнчә, беренче итеп Аллаһ каләмне барлыкка китергән, һәм аңа Кыямәт көненә кадәр буласы барнәрсәне дә язырга әмер иткән.**

- ومن الإيمان بالقدر الإيمان بالارادة والمشيئة.

**– Шулай ук тәкъдиргә ышануга Аның теләгенә һәм ихтыярына ышану да керә.**

فنؤمن بأن ما يجري في هذا الكون إنما هو بإرادة الله ومشيئته.

**Һәм яшәештә ни генә булмасын, ул бары тик Аллаһның теләге һәм ихтыяры аркасында гына булуына ышану.**

فما شاء الله كان وما لم يشأ لم يكن.

**Ул теләгән нәрсә була, һәм Ул теләмәгән нәрсә булмый.**

لا يُسأل عما يفعل- لكمال حكمته وسلطانه - وهم يسألون

**Аллаһ эшләгән гамәлләре өчен соралмаячак, чөнки Ул хәкимлек һәм хикмәт Иясе. Ләкин Ул мәхлукларыннан кылган гамәлләре өчен сораячак.**

- ومن الإيمان بالقدر الايمان بالايجاد والخلق.

**– Шулай ук тәкъдиргә иман китерү – ул Аллаһның барнәрсәне барлыкка китереп булдыруына ышану.**

فنؤمن أن الله خالق كل شيء لا خالقَ غيره ولا رب سواه

**Без Аллаһ бөтен нәрсәне барлыкка китергәненә, һәм Аннан башка барлыкка китерүче юк һәм Аннан башка Раббы юк икәненә ышанабыз.**

وأن كل ما سواه مخلوق فهو خالق كل عامل وعمله وكل متحرك وحركته.

Аллаһтан тыш барнәрсә дә халык кылынган. Аллаһ гамәлне һәм шул гамәлне кылучыны, шулай ук хәрәкәтне һәм шушы хәрәкәтне башкаручыны да барлыкка китергән.

قال الله تعالى : الله خالق كل شيء وهو على كل شيء وكيل.

Аллаһ әйтте: «Аллаһ бөтен нәрсәне дә барлыкка китерүче, һәм Ул барнәрсәне саклаучы».

فمن آمن بالقدر توكل على الله ولجأ اليه.

فالخير كله من عنده سبحانه.

Һәм кем дә кем тәкъдиргә иман китерә икән, ул бары тик Аллаһка гына тәвәккәл кылып, бары тик Аңа гына сыеначак. Барлык хәерлелек тә кимчелекләрдән пакь булучы Аллаһтан.

ومن آمن بالقدر أخذ بالأسباب المشروعة.
لأنها من القدر.

**Сәбәпләр кылу – тәкъдирдән булып тора. Шуңа күрә тәкъдиргә иман китергән кеше шәригатьтә рөхсәт ителгән сәбәпләрен дә кылсын.**

فإهمال الأسباب نقص في العقل ، والتوكل عليها نقص في التوحيد.

**Сәбәпләр кылуны калдыру –акылның тар булуына дәлил, һәм шул сәбәпләргә тәвәккәл кылу –тәүхидтә кимчелек булуына дәлил.**

ومن آمن بالقدر اطمأنت نفسه وثبت عند المصائب لعلمه أنها مُقَدَرة.

**Һәм тәкъдиргә ышанган кешенең йөрәге тыныч һәм мондый кеше бәла-казалар килсә түземле, какшамас була. Чөнки ул бу вакыйгаларның аның өчен алдан ук язылып куйганын аңлый.**

قال تعالى : ما أصاب من مصيبة في الأرض ولا في أنفسكم إلا في كتاب من قبل أن نبرأها إنّ ذلك على الله يسير لكي لا تأسوا على ما فاتكم ولاتفرحوا بما آتاكم والله لا يحب كل مختال فخور

Аллаһ әйтте: «Җирдә яки үзегез белән нәрсә генә булмасын ки, ул инде бу хәл булганчы, китапта язылып куелган. Бу Аллаһ өчен бик җиңел. Һәм бу – үткән нәрсәләргә сез кайгырмас өчен һәм Аллаһ биргән нигъмәтләр белән мактанмас өчен, Аллаһ һәркайсы тәкәбберләнеп мактанган кешене сөйми». Хәдид сүрәсе, 22 аять.